Министерство образования и науки Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Гимназия» г. Мензелинска Республики Татарстан

Принято
Педагогическим советом
МБОУ«Гимназия»
г.Мензелинска РТ
(протокол от 28.08.2020 №1)

Утверждаю
Директор МБОУ «Гимназия»
г. Мензелинска РТ
_________ Халиуллина Г.С.
Приказ от 29.08.2020 № 198

Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа
художественно-нравственной направленности
"Мәктәп сәхнәсе" (Школьная сцена)
Возраст обучающихся: 7-11лет
Срок реализации: 2 года

Программу составил:
педагог дополнительного образования
Гимадеева Р.Б., учитель высшей квалификационной категории

г. Мензелинск, 2020

**Аңлатма язуы**

Өстәмә белем бирү программасы башлангыч гомумбелем дәүләт стандартлары федераль компонентына, “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы”на, Минзәлә шәһәре “Гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең белем бирү программасына нигезләнеп төзелде.

Программа 1-4 нче сыйныф укучылары белән *дәрестән тыш эшчәнлекне* оештыру өчен тәкъдим ителә.

Бу программада балаларның иҗади активлыгын, аралашу әдәбе, актив шәхес рәвеше формалаштыруга зур игътибар бирелә. Программа информация киңлегендә ориентлаша, мөстәкыйль рәвештә яхшы юнәлешне сайлый, чишелеш кабул итә белә торган бала тәрбияләүне максат итеп куя, татар халкының милли хәзинәләрен, җырлы- биюле уеннарын, йолаларын, гореф- гадәтләрен, традицияләрен яктырта.

**Программаның максаты:**

-кече яшьтәге укучыларда эстетик сәнгать рәвеше тәрбияләү өчен уңышлы шартлар булдыру;
-балаларны, үз мөмкинлекләрен оста һәм урынлы файдалана белергә өйрәтү, тормышта югалмыйча мөстәкыйль яшәүче шәхес тәрбияләү;

**Дәрестән тыш эшчәнлек бурычлары:**

1.Укучының шәхси мөмкинлекләрен чынга ашыру һәм сәламәт яшәү рәвеше булдыру.
2.Укучыларда үзе теләгән эшчәнлектә уңай комфорт тудыру;
3.Укучыларда хезмәткә, сәнгатькә, милли культурага карата мәхәббәт тәрбияләү;
4.Балаларда куркынычсыз тормыш һәм гигиена кагыйдәләрен үтәү белән кызыксыну формалаштыру.
5.Ата-аналарның балалар сәламәтлеге белән кызыксынуын булдыру;
6. Үз милли рухың, аңың, республикаң белән горурлык хисе тәрбияләү;
7.Укучыларның дәрестән тыш вакытын кызыклы, файдалы итеп үткәрүгә ирешү;
8.Тәрбия үсешен системалы итеп алып бару;
9.Укучыларда информацион үсеш булдыру;
10.Эшчәнлекне материаль-техник база белән тулыландыру:
11.Милли үзаң формалаштыру.

**Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре:**

– төрле очраклар өчен куркынычсызлык инструктажлары уздыру;
– сәнгатьнең төрле төрләре (театр, концерт, әдәби кичәләр),экскурсияләр, төрле күргәзмәләр, укучыларның иҗади эшләре оештыру һәм уздыру;
– елның төрле вакытларында саф һавада уйнау өчен хәрәкәтле уеннар оештырып уздыру;
– мәктәп, район, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнашу;
–мәктәптә балаларның санитар-гигиеник таләпләрне үтәве буенча эш;
–укучыларны тукландыруны оештыру;
–ата-аналар белән чаралар уздыру;
–юлларда балалар травматизмын кисәтү буенча чаралар уздыру;
–сәнгать әхелләре белән таныштыру.

Үз эшендә педагог балаларның сәламәтлек саклау, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, белемнәрнең максатчан үзләштерелүенә игътибар итәргә тиеш.

Шөгыльләрнең эчтәлеген экияти, уенлы сюжетлар, персонажлар белән тулыландыру кирәк. Уеннар баланың физик үсешенә һәм психикасына уңай йогынты ясый.Ул кече яшьтән кешеләрне, үзен, тормышны яратырга өйрәнсен.Шундый кешенең генә җаны һәм тәне сәламәт була.

Һәр шөгыль балага канәгатьлек, җиңеллек,шатлык хисе алып килергә тиеш.

**«Мәктәп сәхнәсе » программасы эшчәнлегенең көтелгән нәтиҗәләре**

1. Укучыларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.
2. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенүен.
3. Укучыларның сыйныф, мәктәп күләмендә узган чараларда актив катнашуы.
4. Сыйныфның инсценировкалы тамашаларда чыгыш ясавы.
5. Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында тулы мәгълүмат алу.
6. Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
7. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

| **Шәхси нәтиҗәләр:** | **Метапредмет нәтиҗәләр** |
|---|---|
| **Укучыда формалашачак:**<br>- туган ил, халкың һәм тарих өчен горурлык хисе кичерү;<br>үзеңнең милли һәм этник яктан кая керүеңне аңлап, рухи кыйммәтләр булдыру;<br>- дөньяга, аның табигать, халык, мәдәният, дин бергәлегенә карата тулы, социаль юнәлештәге караш формалаштыру;<br>- башка фикерләргә дә хөрмәт белән карарга өйрәнү;<br>- башкаларның хис – тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы – шатлыгын уртаклашу;<br>- үзең өчен җавплылык хисе һәм мөстәкыйлллелекне үстерү;<br>- өлкәннәр һүм яшьтәшләрең белән төрле социаль ситуацияләрдә хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерү;<br>**Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:**<br>-бәхәсле ситуацияләрдән чыгу юлын табу сәләтен булдыру;<br>-куркынычсыз, сәламәт яшәү рәвеше алып бару,<br>-материаль һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл караш формалаштыру | **Танып -белү УУГ**<br>**Укучы өйрәнәчәк:**<br>- укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләү һәм формалаштыру;<br>- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнү;<br>-текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку;<br>-текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү;<br>-укытучының сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү;<br>- информация табу өчен төрле эзләү төрләре , җыю, эшкәртү, анализ, оештыру, тапшыру куллану;<br>**Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:**<br>- предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү;<br>- укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген кыскартып яки, тулыландырып сөйли белү;<br>итә белү (линейка, карандаш, бетергеч…) һәм өстәмә чаралар (информацион һәм коммуникацион технологияләр, белешмә әдәбият һ.б.) куллана белү;<br>- эш сыйфатына бәя бирә белү;<br>-уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белү.<br>**Коммуникатив уку гамәлләре**<br>**Укучы өйрәнәчәк:**<br>-аралашу һәм хезмәттәшлек итү;<br>- бергә утырган иптәшең белән бергә эшләү: эшләрне килешеп үзара бүлешү, үз эшеңне кеше ярдәменнән башка башкару, бер-береңең башкарган эшне тикшерә белү; |

| | |
|---|---|
| | -эшләрне чылбырлап башкару;<br>--төрле фикерләр арасындагы аерманы ишетеп аңлау һәм килешү.<br>**Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак**:<br>- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү;<br>- күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирү;<br>- күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алу;<br>- сөйләмнең диалог формасын үзләштерү<br>**Бәя һәм үзбәя бирү (Регулятив ): гамәлләре**<br>**Укучы өйрәнәчәк:**<br>-бер үк сорауга төрлечә җавап бирү мөмкин икәнлеген аңлау;<br>-үз фикереңне дәлилләү,<br>-үзанализ һәм үзбәя булдыру.<br>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:<br>1) эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү;<br>2) укытучы ярдәме белән уку проблемасын табу һәм формалаштыру;<br>3) укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;<br>4) укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү; |

**Эш формалары:** җанлы әңгәмәләр, әдәби әсәр уку, сәхнәләштерү, курчак театры оештыру, мәктәп һәм шәһәр музейларында дәресләр үткәрү, эзләнү-тикшеренү эшләре башкару, Интернет материаллары белән танышу, китапчыклар ясау, проектлар эшләү, бәйрәмнәр оештыру, театрда булу, сәхнә әсәрләре карау, татар халкының җырларын, күмәк биюләрен, уеннарын өйрәнү, китапханә эшендә,китаплар ремонтлауда катнашу, белем-күнекмәләрне брейн-ринг, Йолдыз сәгате кебек интеллектуаль уеннарда тикшерү, анкеталар үткәрү аша диагностика үткәрү.

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2 ел, 1-4 сыйныф укучыларына исәпләнгән.
**Программа күләме:**
1 нче уку елы: 144 сәгать.
2 нче уку елы: 144 сәгать.
**Укучыларның яше**: 7-11 яшь.

**Программа эчтәлеге**

| Бүлек исеме | Эчтәлек | Сәг саны |
|---|---|---|
| **Без – яшь артистлар.** | Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы | **100** |

| | | |
|---|---|---|
| | турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре өстендә эшләү. Аларны башкару осталыгы, рольләрне башкару, костюмнарны дөрес сайлау серләренә өйрәнү. Балалар өчен язылган җырлар тыңлау (кассета, караокедан). Иң матур җырларны өйрәнү, сәхнәдә башкарырга (аерым, күмәк) әзерләнү. Җырга карата киемнәр сайлау | |
| **Татар халык авыз иҗаты** | Татар халык иҗатының жанрлары белән таныштыру. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү. Сәнгатьле сөйләү өстендә эшләү. Телнең сөйләү үзенчәлеген өйрәнү. | **28** |
| **Сәхнә уеннары 24** | Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълумат бирү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую. Балаларны парлы, күмәк биюләргә өйрәтү (бию элементларын кабатлау, көйгә басу, киемнәр әзерләү). Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау. | **24** |
| **Яңа ел бәйрәменә театр-тамаша** | Яңа ел бәйрәменә әзерлек эшләре алып бару, киемнәр әзерләү. “Яңа ел тамашасы” әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. Спектакльне кабатлау. Музыка. Декорация. Киемнәр әзерләү. Яңа ел бәйрәмендә театр-тамашаны кую. | **30** |
| **Спорт – сәламәтлек ул** | Кызыклы спорт уеннары өйрәтү, күңелле ярыш-эстафета оештыру. Ярыш өчен киемнәр, эмблема әзерләү. Спорт уеннары барышында тәнәфесләр вакытында катнашу өчен биючеләр әзерләү. (Кечкенә һәм өлкән группаларга бүлеп.) | **20** |
| **Г.Тукайның сәхнә әсәрләре** | Г.Тукайның сәхнә әсәрләрен өйрәнү, аның язу стиленә игътибарны юнәлтү. Әсәрләре аша әдәбияткә мәхәббәт тәрбияләү | **20** |
| **А.Алишның әсәрләре** | А.Алишның сәхнә әсәрләрен өйрәнү, аның язу стиленә игътибарны юнәлтү. Әсәрләре аша әдәбияткә мәхәббәт тәрбияләү | **12** |
| **Туган ягым – яшел бишек** | Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. Табигатьне саклауга өлеш кертү: тирә-юньнең чисталыгын саклау, агачлар утырту, чишмәләрне чистарту, кошларга, җәнлекләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәклеген төшендерү. Экологик темага кичә үткәрү. “Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша өйрәнү, чыгыш ясау Туган як, җир турында язучылар язган әсәрләрне уку, фикер алышу.Татарстан гимны, дәүләт | **6** |

| | | |
|---|---|---|
| | символлары белән таныштыру. «Мин яши торган урам, йорт». Үзең яшәгән йортың турында сөйләү. Авыл бәйрәмнәре, урам җыеннары белән таныштыру.<br>. | |
| **Театр тарихыннан** | Беренче барлыкка килгән театрлар тарихы белән танышу. Күрсәтелгән сәхнә әсәрләре, афишалар, куелган урыннары, вакыты белән таныштыру. Беренче театр артистлары. Портретларын, слайдлар карау. Г.Камал “Беренче театр” әсәрен карау. Фикер алышу. | **8** |
| **Милли йолалар һәм бәйрәмнәр** | Халкыбызның гореф-гадәтләре, аларның милли үзенчәлекләре.<br>Каз өмәсе. Орчык өмәсе. Өй күтәрү өмәсе. Табигать һәм без. Туган шәһәребез- Мамадыш төбәгеннән чыккан данлыклы кешеләр тормышы белән танышу**.** Милли бәйрәм -Сабан туе. Сабан туе уеннары, җырлар, биюләр башкару. Милли йола“Каз өмәсе- авыл бизәге”. Слайдлар карау. **.** Җырлы-биюле уеннар өйрәнү. | **40** |
| **Барлыгы** | | **288** |

**Тематик планлаштыру**
**1 нче уку елы**

| № | Бүлек исеме. Тема | Сәг. саны | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|
| 1-2 | **Без – яшь артистлар-40 с.**<br>Театр сәнгате турында төшенчә. | 4 | Курсның бурычлары, дәрестән тыш эшчәнлек белән таныштыру. |
| 3-6 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 8 | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. |
| 7-8 | Сәхнә серләренә өйрәнү. | 4 | Видеоязмалар карау. |
| 9-10 | Киенү-бизәнү осталыгы. | 4 | Декорациянең роле турында әңгәмә |
| 11-12 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Йомры икмәк | 4 | Укучыларның иҗади эшләре. |
| 13-14 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Шалкан. | 4 | .Әкиятне экраннан карау |
| 15-16 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Шалкан | 4 | Рольләрне бүлешү |
| 17-18 | Саф һавада уеннар | 4 | Хәрәкәтле уеннар өйрәнү |
| 19-20 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. | 4 | Укучыларның иҗади эшләре. |
| 21-22 | **Татар халык авыз иҗаты-14 с.**<br>Татар халык иҗаты. | 4 | Җырлар тыңлау |
| 23-24 | Татар халык җыры өйрәнү. Әпипә. | 4 | Татар халык җыры өйрәнү. |
| 25-26-27 | Татар халык биюе элементлары. (малайлар өчен). Татар халык биюе элементлары (кызлар | 6 | Татар халык биюе өйрәнү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өчен). | | |
| 28 | **Яңа ел бәйрәменә театр-тамаша-16 с.** “Яңа ел тамашасы” әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу.Әкиятне сәхнәләштерү. | 2 | Рольләргә бүлеп уку. Сценарийны кабатлау |
| 29 | Хәрәкәтләр.Музыка. | 2 | Сценарийны кабатлау. |
| 30 | “Кыш бабайда кунакта” әкият-кичәгә әзерләнү. Әкият-кичә. | 2 | Әкиятне күрсәтү |
| 31 | Контроль кисем | 2 | Биремнәрне үтәү. |
| 32 | Кышкы урманга сәяхәт | 2 | Чаңгыда йөрү |
| 33 | Саф һавада эстафеталар. | 2 | Хәрәкәтле уеннар өйрәнү |
| 34 | Саф һавада уеннар/ Шәһәрнең музыка мәктәбенә экскурсия. | 2 | Музыка мәктәбе белән танышу. Хәрәкәтле уеннар өйрәнү |
| 35 | Шәһәрнең туган як музеена экскурсия.Табышмаклар кичәсе | 2 | Музей белән ттанышу.Табышмаклар әйтү |
| 36-37 | **Сәхнә уеннары- 10 с.** Такмак, такмаза, тел шомарткычлар. | 4 | Такмак, такмаза, тел шомарткычлар белән танышу. |
| 38-40 | Габдулла Тукай әкиятләре һәм шигырьләрен сәхнәләштерү | 6 | Әкиятләрне һәм шигырьләрне сәхнәләштерү |
| 41-42 | **Сәхнә уеннары-14 с.** Парлы бию элементлары. “Су юлында”. | 4 | Хәрәкәтләрне өйрәнү |
| 43-45 | Күмәк заманча бию элементлары. Зонтиклар биюе. | 6 | Хәрәкәтләрне өйрәнү |
| 46-47 | Күмәк заманча бию. Зонтиклар биюе) | 4 | Чыгыш ясау |
| 48 | **Спорт – сәламәтлек ул- 12с.** Җитезлеккә уеннар | 2 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. |
| 49 | Ярыш-эстафетага әзерләнү. | 2 | Эмблема. Киемнәр әзерләү |
| 50-51 | Саф һавада уеннар | 4 | |
| 52-53 | Ярыш-эстафета. | 4 | Ярыш оештыру |
| 54-55 | **А.Алишның әсәрләре- 12 с.** А.Алишның “Сертотмас үрдәк” театр-тамаша. | 4 | А.Алишның “Сертотмас үрдәк” театр-тамашаның эчтәлеге белән танышу |
| 56-58 | А.Алишның “Сертотмас үрдәк” театр-тамаша. | 6 | Рольләргә бүлеп уку.Сәхнәләштеру. |
| 59 | Язын минем туган шәһәрем | 2 | **Экскурсия оештыру** |
| 60-64 | **Г.Тукайның сәхнә әсәрләре-20 с.** **Г.Тукай әкиятләре сәхнәдә** | 10 | **Г.Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү ”Су анасы”** |
| 65-69 | **Г.Тукай әкиятләре сәхнәдә** | 10 | Рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү. |
| 70 | **Туган ягым – яшел бишек- 6 с.** Табигатькә экскурсия. | 2 | Чишмәләрне чистарту |
| 71 | Арадаш аттестация | 2 | Белемнәрне тикшерү |
| 72 | Минзәлә драмтеатры белән танышу. | 2 | Экскурсия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Барлыгы** | | **144 сәг.** | |

**Көтелгән нәтиҗә:**
-укучыларда драма әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү;
- татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге белән таныштыру;
- сәхнәдә үз-үзеңне дөрес, иркен тоту, аралашу әдәбенә өйрәнү;
-сөйләм телен үстерү;
- алдагы уку елына бурыч һәм максатларны билгеләү.

**Тематик планлаштыру**
**2 нче уку елы**

| N | Бүлек исеме.Тема | Сәг.саны | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|
| 1-2 | **Милли йолалар һәм бәйрәмнәр 40 с.** Бәйрәмнәр бәйрәме. Белем, гыйлем көне.Белем турында шигырьләр уку, тыңлау. | 4 | Түгәрәкнең эшчәнлеге белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.Әлеге уку елына куелган максат, бурычлар белән таныштыру |
| 3-6 | Сөмбелә бәйрәме. | 8 | Көзге балга шигырьләр өйрәнү |
| 7-8 | Уңыш бәйрәме. | 4 | Көзге балны сәхнәләштерү. |
| 9-10 | Өлкәннәр бәйрәме. | 4 | “Минем әбием” сәхнәләштерү. |
| 11-12 | Өлкәннәр бәйрәме. | 4 | Әнием җырлары. Җырлар тыңлау |
| 13-14 | Дини бәйрәмнәр. Рамазан ае мөбарәкбад. | 4 | Дини бәйрәмнәр белән танышу |
| 15-16 | Әкият бездә кунакта. | 4 | Татар халык әкиятләрен сәхнәләштерү. |
| 17-18 | Татар халкынын милли уен кораллары.. | 4 | Жырлар тыңлау, уен коралларын ачыклау. |
| 19 | Милли йола – Нардуган. | 2 | Сайравычлар белән танышу. |
| 20 | Кием – кешенең йөзе. | 2 | Милли киемнәр белән танышу. |
| 21 | **Без – яшь аристлар- 20 с.** “Тавык, Тычкан һәм Көртлек” экияте | 2 | Рольләрне бүлешү |
| 22-23 | “Тавык, Тычкан һәм Көртлек” экияте | 4 | Әкиятне сәхнәләштерү |
| 24 | Милли бәйрәмнәр, музыкаль әсәрләр. | 2 | Музыка тыңлау |
| 25 | «Уз уеныбыз». | 2 | Ижади эшләу. Төркемгә бүленеп уеннар уйлау һәм аны тәкъдим итү. |
| 26 | “Әйтем сүзнең бизәге, мәкаль-сүзнең җиләге”. | 2 | Мәкаль һәм әйтемнәр әйтешү, мәгънәләрен аңлату |
| 27-29 | “Төлке һәм бүре” әкиятен сәхнәләштерү. | 6 | Әкиятне сәхнәләштерү |
| 30 | Бәйрәм өчен | 2 | Җырлы – биюле уеннар уйнау. |
| 31-32 | **Яңа ел бәйрәменә театр-** | 4 | Яна ел тамашасына әзерләнү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **тамаша-14 с.**<br>Яна ел – иминлек алып килсен. | | |
| 33 | **Контроль кисем** | 2 | |
| 34-35 | Яна ел – иминлек алып килсен. | 4 | Яна ел тамашасына әзерләнү |
| 36-37 | Яна ел – иминлек алып килсен. | 4 | Яна ел тамашасына әзерләнү |
| 38 | **Спорт – сәламәтлек ул- 8 с.**<br>Җитезлеккә уеннар | 2 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. |
| 39 | Саф һавада уеннар. Ярыш-эстафетага әзерләнү. | 2 | Эмблема. Киемнәр әзерләү |
| 40 | Саф һавада уеннар | 2 | Саф һавада уеннар уйнау |
| 41 | Ярыш-эстафета. | 2 | Ярыш оештыру |
| 42 | **Театр тарихыннан-8 с.**<br>Беренче барлыкка килгән театрлар тарихы | 2 | Күрсәтелгән сәхнә әсәрләре, афишалар, куелган урыннары, вакыты белән танышу |
| 43 | Беренче театр артистлары. | 2 | Портретларын, слайдлар карау. |
| 44 | Г.Камал “Беренче театр” әсәрен карау. | 2 | Фикер алышу. |
| 45 | Казандагы театрлар торышы, тормышы.. | 2 | Фильм карау |
| 46-48 | **Без – яшь аристлар- 40 с.**<br>Э.Шәрифуллина“Дустың булмаса- эзлә” | 6 | Сценарийне өйрәнә башлау. |
| 49-51 | Э.Шәрифуллина “Дустың булмаса- эзлә” | 6 | Сценариене кабатлау, хәрәкәтләр, биюләр кую |
| 52-54 | Костюмнар әзерләү | 6 | Сценариене кабатлау, хәрәкәтләр, биюләр кую |
| 55-57 | Сценариене кабатлау, хәрәкәтләр, биюләр кую | 6 | |
| 58-62 | Гаилэ бэйрэмнэре. | 10 | Мини әсәрне сәхнәлэштеру. |
| 63-65 | Гаилэ бэйрэмнэре. | 6 | Мини әсәрне сәхнәлэштеру. |
| 66 | **Татар халык авыз иҗаты 14 с.**<br>Мәсәлләр | 2 | Мәсәлләр уку |
| 67-68 | Тапкырлар сандыгы. | 4 | Табышмаклар әйтү, |
| 69-70 | Мәкальләр әйтешү | 4 | Мәкальләр әйтешү |
| 71 | **Арадаш аттестация** | 2 | |
| 72 | Музыкаль кунакханә. | 2 | “Көйне таны “ уенын уйнау. Кечкенә сәхнә әсәрләрен уйнау |
| **Барлыгы** | | **144 сәг.** | |

**Көтелгән нәтиҗә:**
- сәхнәдә үзеңне иркен тоту, фикереңне өздереп әйтү формалаша;
- музыкаль әсәрләрне башкару осталыгының үсүе;
-татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге белән танышып бару;
- Туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү, җырлар, шигъри әсәрләрне өйрәнү;
- театр тарихын белү, беренче театр әсәрләре белән танышу;

**Материаль-техник тулыландыру:**

- төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру;
- укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыру;
- аудиоматериал һәм видеотехника;

- компьютер;
- телевизор;
- проектор,экран һәм башкалар;
- **Кулланма әдәбият**

1. “Әдәбият белеменә кереш” 1998 ел
2. Татар халык әкиятләре. 1997 ел
3. “Тәрбия” газетасы.2009 ел, №4
4. “Ачык дәрес” газетасы. 2010 ел, №5
5. “Җырлыйк әле” җыр китабы. 1997 ел
6. Х. Халиков “Зиһен ачкычлары” 2001 ел
7. “Мәктәп сәхнәсе” китабы.
8. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар.    1997 ел
9. “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
10. Гомәр Бәширов “Туган ягым – яшел бишек”. 1986 ел
11. “Әдәплелек дәресләре”.
12. Татар халык уеннары.Татар халык биюләре. 1997 ел

**Куллану өчен әдәбият.**


1. *Җәләлиева Ш.Ш.* Татар халык педагогикасы. Дәреслек-хрестоматия – К:Мәгариф, 1997.
2. *Нигъмәтов Җ.Г.* Этнопедагогика: халыкчанлык һәм гуманлылык. Югары һәм махсус уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. - . К:Мәгариф, 2002.
3. Воспитание подрастаюәего поколения: идеалы, өенности, ориентиры. Материалы I Республиканского семинара-совещания классных руководителей. – К:РИЦ «Школа», 2004.
4. *Хуҗиәхмхтов Ә.Н.* Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә: Югары һәм махсус уку йортлары өчен педагогикадан уку ярдәмлеге. - К:Мәгариф, 2001.
5. Гаиләм язмышы – илем язмышы: Творческие работы учащихся Республиканского конкурса сочинений, посвященного Году семьи. – К: РИЦ “Школа”, 2008.
6. Көч һәм рух тамырлары. Әдәплелек дәресләре. 1-3 нче сыйныфлар өчен хрестоматия. - К:Мәгариф, 2000.
7. *Галимәрдәнова Р.Н.* Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә экологик тәрбия бирү (Рус һәм татар мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен): - К: “Гыйлем”, 2009.
8. *Исмәгыйлова С.Г., Исмәгыйлова Ф.М.* Тәрбия хәзинәләре. – Чаллы, “КАМАЗ”, 1992.
9. *Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә.* Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү): Методик кулланма. - К:Мәгариф, 2004.
10. Мензелинский край: история и современность /Сост. Ю.Ю.Юсупов, М.Н.Сафиуллин. - К.: ООО «Интер-Графика», 2006.
11. *Сабитов Габделхәй* Урман кызы: Хикәяләр һәм пьеса. – К:Тат.кит.нәш., 1991.
12. *Сабитов Габделхәй*Кайнар туфрак: Хикәяләр. – К:Тат.кит.нәш., 2001.
13. *Сабитов Габделхәй*Ай сукмагы: Хикәяләр, пьесалар. – К:Тат.кит.нәш., 2010.
14. *Шабаев Марс* Гөрләвек: Шигырьләр, әкиятләр. - К:Тат.кит.нәш., 2001.
15. *Гәрәй Рәшит.* Синдә калам: Шигырьләр. - К:Тат.кит.нәш., 1981.
16. *Гәрәй Рәшит.*Көнбагышлар чәчәктә: Шигырьләр. - К:Тат.кит.нәш., 1987.
17. *Гәрәй Рәшит.*Буразналар: Шигырьләр. - К:Тат.кит.нәш., 2007.
18. *Зәйнашева Гөлшат*. Әбиемне яратам. - К:Тат.кит.нәш., 1997.
19. “Мәйдан” журналы. –К:ААҖ “Идел – Пресс”, 2006. - №12.
20. “Аргамак” журналы. – Чаллы: “Аргамак”, 1999. - №3.
21. “Мәйдан” журналы. – К: “Идел-Пресс”, 2003. - №6.

22. “Бәхет биргән җирем – Татарстан”, әхлак дәресе, Р.Әхмәтҗанова, “Мәгариф”, 2012 ел, 8 нче сан, 91 бит.
23. Универсиада дәресе http://kazan2013.ru/ru/education_lesson_method
24. Татарстан Республикасының символлары http://kitaphane.tatarstan.ru/rus/state_symbols.htm
25. Казанның 1000 еллыгы http://kitaphane.tatarstan.ru/1000_Kazan.htm
26. Милли киемнәр. http://tt.wikibooks.org/wiki
27. Wikibooks:Аш-су серләре.Викикитап; http://tatar.com.ru/ash.php
28. Wikibooks:Әкиятләркитабы.Викикитап.
29. Татар исемнәре. http://tatar.com.ru/names.php

Татар электрон китапханәсе. http://kitap.net.ru/

## Календарь- тематик планлаштыру
## 1 нче сыйныф

| № | Бүлек исеме. Тема | Сәг. сан ы | Эшчәнлек төре | Дата | По факту |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-2 | **Без – яшь артистлар-40.** Театр сәнгате турында төшенчә. | 4 | Курсның бурычлары, дәрестән тыш эшчәнлек белән таныштыру. | 2.09 7.09 | |
| 3-6 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 8 | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | 9.09 14.09 16.09 21.09 | |
| 7-8 | Сәхнә серләренә өйрәнү. | 4 | Видеоязмалар карау. | 23.09 28.09 | |
| 9-10 | Киенү-бизәнү осталыгы. | 4 | Декорациянең роле турында әңгәмә | 30.09 5.10 | |
| 11-12 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Йомры икмәк | 4 | Укучыларның иҗади эшләре. | 7.10 12.10 | |
| 13-14 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Шалкан. | 4 | .Әкиятне экраннан карау | 14.10 19.10 | |
| 15-16 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. Шалкан | 4 | Рольләрне бүлешү | 21.10 26.10 | |
| 17-18 | Саф һавада уеннар | 4 | Хәрәкәтле уеннар өйрәнү | 28.10 2.11 | |
| 19-20 | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. | 4 | Укучыларның иҗади эшләре. | 411 9.11 | |
| 21-22 | **Татар халык авыз иҗаты-14** Татар халык иҗаты. | 4 | Җырлар тыңлау | 11.11 16.11 | |
| 23-24 | Татар халык җыры өйрәнү. Әпипә. | 4 | Татар халык җыры өйрәнү. | 18.11 23.11 | |
| 25-26-27 | Татар халык биюе элементлары. (малайлар өчен). Татар халык биюе элементлары (кызлар өчен). | 6 | Татар халык биюе өйрәнү. | 25.11 30.11 2.12 | |
| 28 | **Яңа ел бәйрәменә театр-тамаша-16.** | 2 | Рольләргә бүлеп уку. Сценарийны кабатлау | 7.12 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | "Яңа ел тамашасы" әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу.Әкиятне сәхнәләштерү. | | | | |
| 29 | Хәрәкәтләр.Музыка. | 2 | Сценарийны кабатлау. | 9.12 | |
| 30 | "Кыш бабайда кунакта" әкият-кичәгә әзерләнү. Әкият-кичә. | 2 | Әкиятне күрсәтү | 14.12 | |
| 31 | **Контроль кисем** | 2 | Биремнәрне үтәү. | 16.12 | |
| 32 | Кышкы урманга сәяхәт | 2 | Чаңгыда йөрү | 21.12 | |
| 33 | Саф һавада эстафеталар. | 2 | Хәрәкәтле уеннар өйрәнү | 23.12 | |
| 34 | Саф һавада уеннар/ Шәһәрнең музыка мәктәбенә экскурсия. | 2 | Музыка мәктәбе белән танышу. Хәрәкәтле уеннар өйрәнү | 28.12 | |
| 35 | Шәһәрнең туган як музеена экскурсия.Табышмаклар кичәсе | 2 | Музей белән ттанышу.Табышмаклар эйтү | 30.12 | |
| 36-37 | **Сәхнә уеннары-10**<br>Такмак, такмаза, тел шомарткычлар. | 4 | Такмак, такмаза, тел шомарткычлар белән танышу. | 11.01<br>13.01 | |
| 38-40 | Габдулла Тукай әкиятләре һәм шигырьләрен сәхнәләштерү | 6 | Әкиятләрне һәм шигырьләрне сәхнәләштерү | 18. 01<br>20.01<br>25.01 | |
| 41-42 | **Сәхнә уеннары-14**<br>Парлы бию элементлары. "Су юлында". | 4 | Хәрәкәтләрне өйрәнү | 27.01<br>1.02 | |
| 43-45 | Күмәк заманча бию элементлары. Зонтиклар биюе. | 6 | Хәрәкәтләрне өйрәнү | 8.02<br>10.02<br>15.02 | |
| 46-47 | Күмәк заманча бию. Зонтиклар биюе) | 4 | Чыгыш ясау | 17.02<br>22.02 | |
| 48 | **Спорт – сәламәтлек ул-10**<br>Җитезлеккә уеннар | 2 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 24.02 | |
| 49 | Ярыш-эстафетага әзерләнү. | 2 | Эмблема. Киемнәр әзерләү | 1.03 | |
| 50-51 | Саф һавада уеннар | 4 | | 3.03<br>10.03 | |
| 52-53 | Ярыш-эстафета. | 4 | Ярыш оештыру | 15.03<br>17.03 | |
| 54-55 | **А.Алишның әсәрләре- 12 с.**<br>А.Алишның "Сертотмас үрдәк" театр-тамаша. | 4 | А.Алишның "Сертотмас үрдәк" театр-тамашаның эчтәлеге белән танышу | 22.03<br>24.03 | |
| 56-58 | А.Алишның "Сертотмас үрдәк" театр-тамаша. | 6 | Рольләргә бүлеп уку.Сәхнәләштеру. | 29.03<br>31.03<br>5.04 | |
| 59 | Язын минем туган шәһәрем | 2 | **Экскурсия оештыру** | 5.04 | |
| 60-64 | **Г.Тукайның сәхнә әсәрләре-20**<br>**Г.Тукай әкиятләре сәхнәдә** | 10 | **Г.Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү "Су** | 7.04<br>12.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **анасы”** | 14.04<br>19.04<br>21.04 | |
| 65-69 | **Г.Тукай әкиятләре сәхнәдә** | 10 | Рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү. | 26.04<br>28.04<br>5.05<br>10.05<br>17.05 | |
| 70 | **Туган ягым – яшел бишек-6 с.** Табигатькә экскурсия. | 2 | Чишмәләрне чистарту | 19.05 | |
| 71 | **Арадаш аттестация** | 2 | Белемнәрне тикшерү | 24.05 | |
| 72 | Минзәлә драмтеатры белән танышу. | 2 | Экскурсия | 26.05 | |
| **Барлыгы** | | **144 сәг.** | | | |